**Муса Җәлил**

## Зөбәрҗәттәй алтын...

Зөбәрҗәттәй алтын, гәүһәр сүзләремне
Түгәм сиңа, син шуны да аңламыйсың.
Ачып бирмәк булам бөтен серләремне,
Син  аларны санламыйсың, санламыйсың.
— Ышанмыйм, ди.
Телдә әйтер сүз калмагач,
Җан газабын ничек әйтеп ошатыйм мин?
Ничә әйтеп үзең миңа ышанмагач,
Йөрәгемне ничек ярып күрсәтим мин?

**1923 ел**